ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 март 2018ел № 1241

Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 2 ноябрендәге 5773 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 2 ноябрендәге 5773 нче карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 22 сентябрендәге 5656 нчы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетының «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданлык оборонасы» 03.09, «Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү» 03.10, «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01, «Гомуми белем бирү» 07.02 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына, 2017 елда – 15669,04 мең сум; 2018 елда – 16335,90 мең сум; 2019 елда – 16599,50 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасында:

1 бүлекнең 8 нче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары (мең сум) | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 | 2018 | 2019 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 15669,04 | 16335,90 | 16599,50 | 48604,44 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | | - |
| | Барлыгы | 15669,04 | 16335,90 | 16599,50 | 48604,44 |

- 3 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                   Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 12 мартындагы
1241 нче карарына
кушымта

Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Максат: янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнарның сакланышын күтәрү, аларның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү һәм җиңеләйтү өчен кирәкле шартлар тудыру һәм тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Яр Чаллы шәһәре халкын һәм территориясен саклау буенча янгынга каршы чараларны тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ материаль-техник тәэмин итү | «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ | 2017-2019 еллар | янгыннар саны, берәмлек | 1,0 | 3,0 | 3,0 | 3,0 | 7596,32 | 7513.90 | 7777.50 |
| Бурыч: Шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында «Стрелец-мониторинг» ПАК комплекслы адреслы мониторинг системасына һәм автомат янгын сигнализациясенә техник хезмәт күрсәтү | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | янгыннар саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 3330,97 | 3782,00 | 3782,00 |
| Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә «Стрелец-мониторинг» ПАК комплекслы адреслы мониторинг системасына һәм автомат янгын сигнализациясенә техник хезмәт күрсәтү | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | янгыннар саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 4741,74 | 5040,00 | 5040,00 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Иң яхшы яшь янгын сүндерүчеләр дружинасы» яшь янгын сүндерүчеләр дружиналарының республика смотр-конкурсында катнашу | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| «Белем бирү учреждениеләрендә укучылар арасында «Куркынычсызлык мәктәбе» республика слёт-ярышларында катнашу | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| Укучылар арасында янгынга каршы тематикага иң яхшы инша, иң яхшы рәсем һәм гамәли иҗат өлкәсендә иң яхшы эш конкурсында катнашу | Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2017-2019 еллар | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| БАРЛЫГЫ: | | | | | | | | 15669,04 | 16335,90 | 16599,50 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова